| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 23.11.2018 Казан ш. № 10-68/кс

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 1 декабрендәге 10-97/кс номерлы карары белән билгеләнгән «Саба районының Шәмәрдән ТКХ КЖП» ачык акционер җәмгыяте өчен 2019 елга каты коммуналь калдыкларны күмүгә озакка исәпләнгән чик тарифларга төзәтмәләр кертү турында

"Җитештерү һәм куллану калдыклары турында" 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында" 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең "Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында" 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2019-2020 еллар өчен озакка исәпләнгән тарифларны үзгәртү максатларында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Саба районының Шәмәрдән ТКХ КЖП» ачык акционер җәмгыяте өчен 2018 – 2020 елларга каты коммуналь калдыкларны күмүгә һәм эшкәртүгә чик тарифлар билгеләү турында" 2017 елның 1 декабрендәге 10-97/кс номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылган көннән соң 10 көн эчендә үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының карарының 1нче кушымтасы
01.12.2017 № 10-97/кс
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
23.11.2018 № 10-68/кс
номерлы карары редакциясендә)

«Саба районының Шәмәрдән ТКХ КҖП» ачык акционер җәмгыяте өчен
каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2018 – 2020 елларга календарь бүленешле чик тарифлар

| т/б № | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекнең, оешманың исеме | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик тарифлар, сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | Саба муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | «Саба районының Шәмәрдән ТКХ КҖП» ачык акционер җәмгыяте* | 88,28 | 88,28 | 88,28 | 132,53 | 125,34 | 125,34 |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының карарының 2нче кушымтасы
01.12.2017 № 10-97/кс
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
23.11.2018 № 10-68/кс
номерлы карары редакциясендә)

«Саба районының Шәмәрдән ТКХ КЖП» ачык акционер җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2018 – 2020 елларга чик тарифларны җайга салуның озак вакытка каралган параметрлары

| № т/б | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашыручы оешманың исеме | Ел | Операцион чыгымнарның нигез дәрәҗәсе | Операцион чыгымнарның нәтиҗәлелеге индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | электр энергиясенең чагыштырма кулланылышы |
| | | | мең сум | % | % | кВт·сәг./куб.м |
| 1 | «Саба районының Шәмәрдән ТКХ КЖП» ачык акционер җәмгыяте | | | | | |
| 1.1 | Каты коммуналь калдыкларны күмү | 2018 | 2386,15 | 1 | - | - |
| | | 2019 | 2470,96 | 1 | - | - |
| | | 2020 | 2529,42 | 1 | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге